КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫНЫЩ ОБЪЕКТОВМИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

14.11.2018

№ 47

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында

2014 елның 21 июлендәге “Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында” гы 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы иҗтимагый совет турында”гы карары нигезендә: БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагында Иҗтимагый совет оештырырга.
2. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагында Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне расларга.
3. Әлеге боерык Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Рәис: И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 2018 елның 14
ноябрендәге 47нче боерыгы белән
расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ КОМИТЕТЫ КАРАМАГЫНДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ТУРЫНДАГЫ НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты карамагындагы киңәшләшү органы, ул Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәнә мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләти саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырган һәм тормышка ашырган вакытта гражданнарның хокуклары һәм иреге һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук Комитет карамагындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәдә каралган (алга таба - Нигезләмә) башка вәкаләтләрне башкара.

1.2. Иҗтимагый советның саны һәм составы Комитет боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомство карамагындагы Иҗтимагый совет оештыру тәртибе нигезендә раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук бу Нигезләмәгә таяна.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары киңәш итү рәвешендә.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмгыяви башлангычта башкара.

1.6. Иҗтимагый совет эше ирекле нигездә, ачыклык һәм партнерлык принципларында һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә төзелә.

1.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге гражданнар җәмгыяте, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынучанлыгы нигезендә башкарыла.

## 2.Иҗтимагый советның эшчәнлек максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып түбәндәгеләр санала:

гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәнә мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләти саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырган һәм тормышка ашырган вакытта гражданнарның хокуклары һәм иреге һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмаларның хокукларын яклау;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге “Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре” (алга таба – Комитет турындагы Нигезләмә) карары белән расланган Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә Комитет компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә иҗтимагый, профессиональ һәм иҗади берләшмәләрне җәлеп итү; Комитет эшчәнлегендә ачыклык принципларын тормышка ашыру;

Комитет тәкъдим иткән дәүләт хезмәтләренең сыйфатын иҗтимагый контрольдә тотуны көчәйтү, Комитет эшчәнлеге өлкәсендә законлылык, ачыклык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

Комитет турындагы Нигезләмә буенча Комитет компетенциясенә кергән өлкәләрдә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәнә мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләти саклау өлкәсендә дәүләт сәясәте мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый акилар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

Комитет караралар кабул иткән вакытта иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Комитет эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын арттыту.

2.3. Аның эшенең нәтиҗәләреннән чыгып, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисади, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып, Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары үзгәрә ала.

## 3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый советның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт

комитеты, Ведомство карамагындагы Иҗтимагый совет оешыру тәртибе нигезендә формалаштырыла.

3.2. Иҗтимагый совет Комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә аның составында 11 кеше ирекле катнашу нигезендә формалаштырыла.

3.3. Иҗтимагый совет составына шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм башка социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма вәкилләре булган Россия Федерациясе гражданнары керә ала. Шул ук вакытта аларның профессиональ сыйфатлары, тиешшле белеме булу-булмау, Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр хакында фикер алышу өчен кирәкле өлкәдә эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына бу пунктның беренче абзацында аталган затлар белән бергә Татарсткан Республикасы Иҗтимагый советы тәкъдим иткән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомум санының яртысыннан кимрәген тәшкил иткән санда затлар кертелә.

Иҗтимагый совет составына элегрәк Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт гражданнар хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүдәт вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт гражданнар хезмәт вазифаларын, муниципаль вазифалар һәм муниципаль хезмәт вазифаларын башкарган, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомум санының биштән береннән артмаган санда затлар керә ала.

3.4. Россия Федерациясендә дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт гражданнар хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүдәт вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт гражданнар хезмәт вазифаларын, муниципаль вазифалар һәм муниципаль хезмәт вазифаларын башкарган, суд карары нигезендә акылга зәгыйфь дип табылган, бетмәгән яки төшерелмәгән суд хөкеме булган, шулай ук 2005м елның 4 апрелендәге “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында”гы 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаган затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмый.

3.5. Иҗтимагый советның персональ составы Комитет боерыгы нигезендә раслана.

3.6. Иҗтимагый советның составы расланган көннән 30 көнгә дә соңга калмыйча Комитет Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның рәисе һәм урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү нәтиҗәсендә Иҗтимагый советның гомум әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.7. Иҗтимагый совет рәисен яки урынбасарын вазифасыннан азат итү мәсьәләсе Иҗтимагый совет тарафыннан Комитет рәисе мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисе яки урынбасарының шәхси гаризасы яки Иҗтимагый

советның гомум санының биштән бер өлешеннн кимрәген тәшкил итмәгән Иҗтимагый совет әгъзалары төркеме тәкъдиме буенча карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомум санынннан күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.8. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибен билгели.

3.9. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләр вакыты яңа формалаштырылган Иҗтимагый совет составының беренче утырыш үткәргән көннән соң өч ел тәшкил итә.

3.10. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Комитет рәисе боерыгы нигезендә Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча түбәндәге очракларда туктатыла:

аңа Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары нигезендә җинаять кылуда гаепләү белдерлегән очракта;

аңа административ арест рәвешендә административ җәза билгеләнгән очракта;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайлана торган вазифага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы кешесе яки вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәгән вакытта, шулай ук аның Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

3.11. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре түбәндәге очракларда тәмамлана:

вәкаләтләре вакыты беткән очракта;

ул Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза язган вакытта;

сәламәтлек торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаган очракта;

аңа карата судның гаепләү карары законы көченә кергән очракта;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә акылга зәгыйфь яки хәбәрсез катнашмаучы дип тапкан очракта;

утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә Иҗтимагый совет карары буенча;

системалы рәвештә (өч тапкырдан күбрәк) Иҗтимагый совет утырышлары эшендә сәбәпсез катнашмавы;

системалы рәвештә (ике тапкырдан күбрәк) Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарының йөкләмәләрен сәбәпсез үтәмәү;

аны Россия Федерациясендә дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт гражданнар хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында дәүдәт вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт гражданнар хезмәт вазифаларын, муниципаль вазифалар һәм муниципаль хезмәт вазифасына билгеләү;

аның чит ил гражданлыгы алуы;

Россия Федерациясе гражданины булудан туктавы.

3.12. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре бетү Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарының тәкъдиме, шулай ук бу Нигезләмәнең 3.11 пунктында каралган очраклар ачыкланганда.

Иҗтимагый совет әгъзасы бу Нигезләмәнең 3.11 пунктыныңы дүртенче, бишенче, унынчыдын уникенчегә кадәр абзацларында каралган хәлләр туган очракта, Иҗтимагый совет рәис яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Комитет башлангычы белән үткәрелгән барлык чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, “түгәрәк өстәлләр”) катнашырга, федераль законнар нигезендә дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр, шәхси мәгълүматлар турында белешмәләр һәм чикләнгән мәгълүматлар файдаланылган чаралар искәрмә булып тора;

инициатив тәртиптә Иҗтимагый советка аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм җибәрергә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш тәртибенә һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет утырышларына көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен чакырыла торган кешләрнең кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне үтәргә;

бу Нигезләмәдә каралган Иҗтимагый советның эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга;

Иҗтимагый совет тарафыннан үзенә салынган бурычларны хәл итү өчен оештырылган эксперт, эш төркемнәр, комиссияләр, башка эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышларында расланган планнар һәм программалар нигезендә оешыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен оештыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет һәм Комитет рәисе тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да кимрәк оештырылмый. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар юеркетмә белән теркәлә.

Иҗтимагый совет утырышлары Комитет башлангычы буенча Комитет тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнгән норматив хокукый акталар һәм башка документлар исемлеге белән каралган Иҗтимагый совет нәтиҗәсен бирү өчен үткәрелә. Алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 мартындагы "Әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы Иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышмыйча кабул ителә алмаган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар һәм башка документларның составын раслау турында"гы 214нче карары белән расланган әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышмыйча кабул ителә алмый. Иҗтимагый совет бу Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актларның проектларын (норматив хокукый актлар) Комитет Иҗтимагый советка җибәргәннән соң ун календарь көн дәвамында карый.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары Иҗтимагый советның кимендә өчтән ике әгъзасы катнашкан вакытта хокукка ия дип санала. Утырышта катнаша алмаган Иҗтимагый совет әгъзасы алдан Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарына яки Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибенә хәбәр итеп, көн тәртибенә куелган сораулар буенча үз тавышы яки фикерен язма рәвештә, факсимиль яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына бирә ала. Иҗтимагый совет әгъзалары утырышында катнашучылар санына үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырганнар да кушыла.

Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый совет нәтиҗәен бирү максатларында тавыш бирүне үткәрү нәтиҗәләрне беркетмәгә кертеп, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларыннан сораштыру рәвешендә читтән торып тавыш бирү юлы белән башкарыла. Беркетмәне Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаган очракта рәис урынбасары имзалый.

Мондый тавыш бирү тапшырылган һәм кабул ителгән хәбәрләрнең дөреслеген раслаучы почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки башка элемтә ярдәмендә документлар алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш үткәрелгән вакытта рәис урынбасары, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына үл үткәрелергә җиде көннән дә соңга калмый, тәкъдим ителгән көн тәртибе, Иҗтимагый совет нәтиҗәсе чыгарылырга тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә. Кирәк булган очракта Иҗтимагый совет әгъзалары Комитеттан аралырга тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат ала.

Иҗтимагый совет карары күпчелек тавыш белән чыгарыла. Тавышлар тигез булган очракта, Иҗтимагый совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Кирәк булган очракта Иҗтимагый совет карары белән эшче төркемнәр оештырыла.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ул булмагн очракта - Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары үткәрә.

5.6. Иҗтимагый советның үзенә салынган максат, бурыч, вәкаләтләр нигезендә кабул ителгән карарлары киңәш бирү рәвешендә һәм Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый1 совет утырышы беркетмәсеннән өземтә сыйфатында кызыксынган кешеләргә җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчшнлеге турындагы мәгълүмат Комитетныңм “Интернет” мәгълүмти-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе :

Иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомум җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет киңәшмәләрен алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эше планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый советка раслауга куя.

Иҗтимагый совет утырышларын әзерли;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый советның киңәшләрен, беркетмәләрен һәм башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларының вакытын һәм үткәрү урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлегенең максатлары һәм бурычлары кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән запросларны, киңәшләрне, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатмаларны һәм мөрәҗәгатьне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен башка функцияләрне үти.

5.9. Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаганда аның вазифаларын башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерли;

Иҗтимагый совет утырышлары өчен көн тәртибен төзи һәм аны раслау өчен рәискә бирә;

Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм беркетмәләр проектларын әзерли;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышының кайда үтәчәген һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет белән Комитетның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлегенең документ-техник тәэмин ителешен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен терки һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерә.

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлау һәм фикер алышуга сораулар әзерләү өчен эшче, эксперт төркемнәргә һәм башка эшче органнарга берләшә, материаллар әзерләүгә Иҗтимагый совет рәисе

урынбасары белән килештереп, Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне чакыра ала.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр, экспертлар, Иҗтимагый совета карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм өземтәләр бирү өчен башка белгечләр чакырыла ала.

Иҗтимагый совет әзгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет утырышында Иҗтимагый совет чакыруы буенча катнаша ала.

Иҗтимагый совет эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатаәгъзалары катнашуны тәэмин итә.

5.13. Иҗтиманый советка каралырга кертелгән материаллар ул каралырга тиешле Иҗтимагый совет утырышы билгеләнгәни көнгә ун көн кала Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына бирелергә тиеш. Материалларны соңгарак калып бирү Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең оештыру-техник якларын Комитет башкара.